КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 16 март г.Казань № 210

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 30 декабрь, 1216 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне аякка бастыруга һәм үстерүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне аякка бастыруга һәм үстерүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2025 ел, 30 декабрь, 1216 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне аякка бастыруга һәм үстерүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Субсидия турында мәгълүмат субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – «Бюджет» бүлегендә) урнаштырыла.»;

2.16 пунктта «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.5 пунктта:

икенче абзацта «субсидияләрне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчаларын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык әлеге пунктның беренче һәм икенче абзацлары нигезендә субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару өчен нигез булган хәлләр ачыкланган көннән 30 календарь көннән артмаган срокта Субсидия алучыга таләп алынган көннән 10 календарь көн эчендә субсидия акчасын кире кайтару турында таләп җибәрү юлы белән субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтаруны тәэмин итә.»;

3.6 пунктта «субсидияне кире кайтарудан» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтарудан» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                    А.В.Песошин